ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-19; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**
№4 от «1» апреля 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Келәүш авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияле исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, “Күмү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законы, “Татарстан Республикасында “Күмү һәм җирләү эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” 2007 ел, 18 май, 196 нчы карары, Россия Федерациясе Дәүләт Хакимиятенең “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 нчы елның 1 апреленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче Б.В.Иванов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
01.04.2019 ел, 4 нче санлы карарына
1 нче № кушымта

2019 елның 1 апреленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегендә җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле
булган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2735,40 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 712,75 |
| Кабер казу һәм җирләү | 2498,32 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Җитәкче Б.В.Иванов

Татарстан  Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
01.04.2019 ел, 4 нче номерлы карарына
2нче № кушымта

2019 елның 1 апреленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегендә җирләү  буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта,хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү | 848,64 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 1964,43 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 727,18 |
| 5.Кабер казу һәм җирләү | 2406,22 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Җитәкче  Б.В.Иванов